# Һөнәр— ил канаты

**Мирза МӘХМУТОВ, академик**

Мирза Исмәгыйль улы Мәхмутов исеме бездәге һәм чит илләрдәге фәнни һәм педагогик җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Ул — проблемалы укыту теориясенә нигез салучы, гарәп һәм төрки телләр галиме, педагогика буенча куп хезмәтләр авторы, мәгариф өлкәсендә җитәкче, җәмәгать эшлеклесе. Россия Белем академиясе һәм Татарстан Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы, педагогия фәннәре докторы, профессор, Россиянен атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Дәүләт премиясе лауреаты.

### I. Кенәрилек.

Болгавыр заман уй-фикеребезгә, аңыбызга үзгәрешләр кертте һәммә кеше акча турында сөйли, хезмәтнең сыйфаты турында гына түгел, үзе турында да онытылды. Мөгаен, адәм баласын шаккатырган бу дәвер утәр әле, тик җәмгыятькә генә чиксез күп төзәлмәс яралар ясалыр, намуслы һәм тыйнак, якты киләчәккә ышанган миллионнарча кешеләрнең язмышлары гына бозылыр. Илебездә җитештерү һәм товар эшләп чыгару да җайга салыныр, кешеләр көндәшлеге һәм товарлар бәйгесе, белү һәм уңышка ирешү аша юньлерәк тормыш та килер. Әлегә моның кайчан буласын гына әйтүе кыен.

Җәмгыятьнең үсеш кануннары арасында кирәклелек һәм җитәрлек булу дигән принцип бар. Татар халкының тәрәккыяте өчен зарури шартлар нәрсәдән гыйбарәт соң?

Кешелек дөньясы туплаган тәҗрибә күрсәткәнчә бихисап казылма байлыклары (нефть, руда, күмер һ. б) булган милләт тә бары тик үз хезмәте хисабына гына исән кала һәм усә ала. Ләкин «абстракт» хезмәт кенә җитми. Житештерүчәнлекне арттыру өчен төп шартлар — хезмәтне, эшне яхшы оештыра алу, эшләүченең хезмәте максатлы булу, аны башкарырга теләк, ихтыяҗ, мотив булуы мөһим...

Җитештерүдә һәм кеше эшчәнлегенең аңа бәйле башка өлкәләрендә без элек күз алдына да китермәгән үзгәрешләр бара; моның дөньякүләм тенденцияләре бар. Бүген инде теориядә генә түгел, гамәлдә да хезмәтнең интеллектуальләшүе, җитештерүнең магълүматлашуы, роботлашуы һәм компьютерлашуы ачык күренә Алар, кирәкле һәм җитәрлек шартлар буларак, бүгенге социаль икътисади тәрәккыятнең нигезе булып тора. Электроника алга киткән илләрдә тел җитештерү

чараларының берсенә әверелеп бара: һәр гаиләдә телевизор, суыткыч, микродулкын миче, видео һ б. ш. бар. Чит илләрдә (мәсәлән,технологик эрага кереп баручы Япониядә) яктыртылмый торган цехлар һәм заводлар бар. Аларда продукция кеше катнашыннан башка гына эшләп чыгарыла! Мәсәлән, телевизорларны автоматлар, роботлар ясый. Кеше цехка детальләрне үзеннән дә төгәлрәк эшкәртә ала торган автоматларның эшен тикшерү өчен генә керә. Анда эшләнгән товар күбрәк һәм арзанрак кына түгел, югары сыйфатлы, дөнья базарында өстенрәк булырлык. Ә бу — җәмгыятьнең яшәү һәм алга китү шартларының иң мөһиме.

Табигый ки, мондый җитештерүгә компетентлы, мәгълүматлы, тирән белемле кешеләр генә хезмәт күрсәтә. Бу очракта һөнәр төрләре үзгәрәме соң? Әлбәттә, үзгәрә, чөнки анда төп һөнәр — көйләүче (кул хезмәте күп кулланыла торган безнең предприятиеләрдәге кебек, токарь һәм слесарь түгел). Алга киткән илләрдә нинди инженерлык һөнәрләре киңрәк таралган соң? Проектлаучы, электрончы, диагностикалаучы, программалаучы h. б., ягъни күбесенчә яңа технология (know-how— «белә-ничвк») белән эш итүчеләр.

Әйе, галимнәр яңа технологияләр уйлап табалар һәм аларны гамәлгә кертәләр, һөнәрләр исемлеге дә тиз үзгәрә. Мәсәлән, алга киткән илләрдә технологик яктан яхшы җиһазланган машина төзү тармагын 60—70 нче елларда ук инде токарь, слесарь яки фрезерчы кебек тар профильле эшчеләр канәгатьләндерми башлады. Җитештерү автоматлаша һәм роботлаша барган саен, киң профильле эшчеләр — күп төрле кыру, фрезерлау, револьвер станокларында эшли ала торган токарь-универсал, электр һәм ацетилен белән, төрткеләп эретеп ябыштыручылар күбрәк кирәк була башлады. Конвейерларны, автомат станокларны һ. б. көйләүче киң профильле слесарьларга да ихтыяҗ бик тиз артты. Хәзер инде җитештерү ечен оста эшчене алыштырырлык техниклар кирәк. Шуңа.күрә дә, санлы программа белән идарә ителә торган станоклар янына күбрәк техниклар, хәтта инженерлар баса. Бу безнең Казан һәм Чаллы заводларында да күренә башлады инде.

Бүген югары җитештерүчәнлекне һәм дөнья базарында көндәш булырлык товарларны гади эшче, техник һәм инженер түгел, югары дәрәҗәдә әзерлекле һөнәр иясе гена бирә ала. Димәк, кадрлар әзерләгәндә һөнәрне дерес сайлау, специальләшү төп мәсьәлә булып тора. Демократия шартларында идарә итү мәсьәләләре дә һәр кимәлдә (дәүләт белән идарә итүдән алып, эшче яки хезмәткәрләрнең кечкенә төркемнәре белән идарә итүгә кадар) күпкә катлаулырак.

Хәзерге техника һәм технологиянең тиз үзгәрүе, инженер-техник фикернең уку йортларында бирелә торган белемнән узып китүе шартларында хезмәткәрләрнең функциональ белемсезлеге күзәтелә. Белем — корал ул. Халык әйтмешли, «корал кемнеке — заман шуныкы». Димәк, өзлексез белем бирү системасын төзергә, һөнәри белем бирүне тамырдан үзгәртеп корырга кирәк. Ул массакүләм, шул ук вакытта һәр кеше өчен өзлексез булырга тиеш. Даими өйрәнүгә сәләтле кешеләре күп булган милләт кенә алга чыга алачак. Шуңа күрә, шәхеснең фикерләү сәләтен үстерү белән бергә, аның өйрәнүчәнлеген дә тәрбияләргә кирәк.

Бу очракта яшьләрне хезмәткә ничек әзерләргә? Аларны кайсы һөнәрләргә җәлеп итәргә? Нәрсә дә булса эшләү һәм эш башкарудан тыш, төрлечә тәрбияләнгән кешеләр белән аралашу осталыгын; тиз элемтә урнаштыра белүне; әдәпле, инсафлы, шәфкатьле булуны таләп итүче, даими киңәя баручы хезмәт күрсәтүгә укучыларны, студентларны ничек әзерләргә?

Монда илебездәге хәлне генә түгел, бөтендөнья үсү тенденциясен дә исәпкә алу зарури.

Гасыр азагында алга киткән илләрнең иҗтимагый структурасы үзгәрде. Мәсәлән, XX асыр башында АКШның авыл хуҗалыгында халыкның 87 проценты эшләсә, хәзер 5 проценты гына. Гасыр урталарында промышленностьта (сәнәгатьтә) халыкның 70 проценты эшләсә, хәзер ул сан 15 проценттан да кимрәк. Кул хезмәте кими барганлыктан, белемнең әһәмияте арта. XXI гасыр башында халыкның 75 проценты укуга, өйрәнүгә җәлеп ителәчәк (World almanac, 1996, USA). Шундый ук тенденция Россиядә дә күзәтелә. Димәк, тимер, нефть, күмер түгел, ә бәлки интеллект (акыл, фикерләү сәләте) һәм технология якын киләчәктә иң зур байлык булачак. Илебез булдыклы, кыю, иҗади фикерләүче кешеләргә мохтаҗ. Аларны балачактан, мәктәптә үк тәрбияли башларга кирәк. Бу эш Япониядә, АКШта һәм алга киткән башка илләрдә күптәннән бара инде. Безгә җитәкчеләрнең дә эшне элеккегечә оештыра торганнары түгел, кешеләрнең мәнфәгатен аңлап, аларның күңелен күрә белүче замана мәнәҗерләре (менеджерлары) кирәк.

Татар милләтенең язмышы, үсү перспективасы алда бәян ителгән хезмәт шартлары белән тыгыз бәйләнгән. Шуннан чыгып, Татарстанда шәхеснең нинди сыйфатлары,тәгълим-тәрбия бирүнең кайсы юнәлешләре өстенлек алырга тиешлеген билгели алабыз.

Профессиональ (һөнәри) белемнең әһәмияте зур диюче (уңай карашлы) укучы, студентлар — 50%, эшләүчеләр — 60%; коммерсант (сәүдәгәрләр): Казанда — 46%, район үзәкләрендә— 50%, авылларда — 35%, башка зур шәһәрләрдә — 33%.

Алга киткән индустриаль илләрдә өстенлек күптәннән инде профессиональ тәгълимгә бирелә. Анда теләсә кайсы эшләүченең югары осталыгы, профессионализмы зур кыйммәт санала. Шуңа күрә аларның товарлары һәрвакыт югары сыйфатлы һәм дөнья базарында үтемле, безнеке беркемгә дә кирәк түгел! Бушлай бирсәң генә алалар (АКШ бөтендөнья продукциясенең — 26% ын, Япония — 18%, Россия  1% ын җитештерә).

## II. «Әйдә, татарча укытыйк».

Бәйсезлек өчен көрәш юлына бастык. Хәзер инде милли мәгарифне үстерү өчен иҗтимагый-сәяси шартлар да тудырырга тиешбез. Иң мөһим шартларның берсе — татарча һөнәри белем бирү. Тел үсү законнары татар теленең һәрбер хезмәт өлкәсендә кулланылуын, барлык һөнәр кешеләренең ул телдә сөйләшүен, фикер алышуын, татарча лекцияләр укуны һәм тыңлауны, кинофильмнар һәм телетапшырулар карауны һ. б. таләп итә.

Татарстанда заманча белемле милли кадрлар әзерләү өчен шартлар бармы?

Республикада гомуми һәм һөнәри белем бирү системасы булдырылды. Планлы икътисад һәм тоталитар режим шартларында ул, У. Черчилль әйтешми, «чабаталы Россияне атом кораллы» итте һәм үзен аклады Татар телендә урта белем бирә торган милли мәктәбебез бар... Тик боларны тәрәккыят шартларына, базар икътисадына һәм кешеләр арасындагы күркәм мөгамәләгә яраклаштыру таләп ителә.

Татар телендә иртәгәсе көн һөнәриләрен (профессионалларын) әзерләү мөмкинме? Теоретик яктан — әйе, мөмкин. Ә гамәлдә ничек соң? Мәгълүм булганча, һөнәри белемнең өч кимәле бар: башлангыч (эшче, кече хезмәткәр), урта (җитештерүдә һәм хезмәт күрсәтүдә катнашучы барлык урта буын һөнәриyләре), югары (бакалавр һәм белгеч). Татар теле дәүләт теле булуга карамастан, хәзерге вакытта Татарстанда, берничә авыл хуҗалыгы һөнәр училищесында кайбер фәннәрне укытуны исәпләмәгәндә, татарча һөнәри белем бирү юк әле. Элек-электән татарлардагы милли мәгариф кайбер мәдрәсәләрдә приказчик һәм хисапчылар әзерләүне исәпкә алмаганда) гомуми белем генә биргән. Игенче һөнәре гаиләдә, хезмәт шартларында үзләштерелгән. XX гасырда Россиядә барлык рус булмаган милләт балаларына һөнәри белем русча гына бирелде. Татар теле индустрия шартларында элек кулланылмады. Хәзер аның кулланылу даирәсен киңәйтүгә икътисади ихтыяҗ бармы? Халыкта моңа омтылыш сизеләме? Матди-техник шартлар булдырылганмы, кадрлар әзерләнгәнме?

Татар мәктәпләренең саны арту сәбәпле, гомуми белем мәктәпләрендә татар теле укытучылары җитешми Һөнәри белем бирү өчен татарча укыта ала торган укытучы-инженер, химик, агроном, технологлар, медик, электрончы, программалаучы, экономистлар, мәнәҗерләр һ. б. кирәк. Техник, экономик, юридик, технологик фәннәрне татар телендә сыйфатлы итеп укытучылар юк дисәк, дөрес булыр. Мәсәлән, мәнәҗерләр әзерләүгә зур ихтияҗ туды. Ләкин аларны вузларда һәм техникумнарда да тиешенчә укытырлык кешеләр юк әле. Дөнья экономикасы фәнен татарча укыта алырлык белгечләр кайчан булыр? Мондый сорауларга әлегә җавап табып булмый.

Җәмгыятебезнең демократиянең кайбер сыйфатларын үзләштерә баруы нәтиҗәсендә, соңгы елларда татарча укуга күп дистә мең татар балаларын, хәтта бераз рус балаларын да тарту мөмкин булды. Әмма, милли хәрәкәт дулкыннары кими барган саен, татар теле белән кызыксынуның русларда гына түгел,татарлар арасында да сүнә баруы сизелә. Кайбер ата аналар балаларын рус мәктәпләренә күчерә башлады һәм алар моны «татар мәктәбендә начаррак укыту» белән аңлата Шулай булгач, безнең энтузиазмның кая хәтле алып барасын фараз ител булмый.

1997 елда республикабызда гомуми белем мәктәпләре өчен бер меңнән артык татар теле укытучысы җитмәвен исәпкә алсак, һөнәри белемне татар теленә кучерунең никадәр катлаулы булуын да аңларга мөмкин. Әлбәттә, педагогика университетында, архитектура-тезелеш, мәдәният һәм сәнгать академияләрендә татарча укыту буенча бераз тәҗрибә тупланды, энтузиаст галимнәр тарафыннан программалар эшләнде һәм кайбер дәреслекләр язылды. Суз дә юк, тырышлык бушка китмәячәк, гәрчә беренче тәҗрибәләр аерым-аерым, системасыз булса да.

Бу турыда тагын берничә сүз әйтеп үтмичә булмый, чөнки галимнәр, кыю теоретик фикерләр белдерү белән бергә, зур тәҗрибә эшләре дә алып баралар Мәсәлән, «Татар телендә югары белем бирү мәсьәләләре» (Казан, 1997) исемле фәнни-методик җыентыкта төрле-төрле мәкаләләр урнаштырылган. Авторлар узләренең укыту тәҗрибәләре, «Сызма геометрия», «Теоретик механика» дигән китаплар, дәреслек-кулланмалар бастырып чыгарулары турында язалар.

Милләт өчен янып йөрүчеләрнең берсе — Рәшит Шакир (Р. Ә. Шакирҗанов) үзенең теоретик мәкаләсендә татар телен торгызу, аны үстерү һәм куллану кирәклеген исбатлый; аны өйрәнү — диалектик фикер йөртү мәктәбе, ди; моның дөньяны дөрес танып белүгә һәм фәнне үстерүгә, җәмгыятьнең тәрәккыятенә ярдәм итәчәген күрсәтергә омтыла.

Р. Шакир, телгә лингвистик анализ ясап һәм аны рус теле белән чагыштырып, «татар телендә фикерләү һәм танып белү тәртибе үзгә» дигән нәтиҗәгә килә. Мәсәлән Г. Тукайның «чыктым аркылы күпер» тәнкыйди җөмләсенә таянып, ул логик фикер йөртә «Мин күпер аша чыктым» кебек җөмләдә алдан — фикер, аннары гамәл булуны танып белү өчен зур өстенлек дип карый, чөнки рус телендә алдан гамәл, аннары фикер булу («я прошел через мост») диалектикага бик ук туры килми, ди. Автор «...татарча фикерләү хәрәкәтне төрле яктан, ныклап, төгәлрәк өйрәнергә мөмкинлек бирә» дигән нәтиҗәгә килә.

Минемчә, хәбәрнең җөмлә азагында булуы гына фикерләү сәләтен киметми дә, арттырмый да. Шул ук җөмләдә, мәсәлән, гарәп телендә дә хәбәр алда килә («Зәхәбтү габра аль-җиср»), инглиз телендә дә шулай ( «I passed over the bridge»). Телләрдә синтаксик яки морфологик аерма булу табигый, ләкин бу аларның сыйфатын билгеләми. Тегe яки бу телнең өстенлеген аның сүз байлыгы, сионимнар, терминнар күплеге һәм телнең кулланылу ешлыгы күрсәтә.

Татар телен үстерергә омтылучы энтузиаст-галимнәребез татар телендә һөнәри белем бирү кирәклегенә, мөһим булуына инанганнар, әлбәттә. Тик башка сораулар да туа. Демократия, кешенең ихтыярын, теләген хөрмәт итү, аңа һөнәрне, эш һәм яшәү урынын, телне һәм уку йортын һ. б. сайлау мөмкинлеге бирү шартларында без татар яшьләрен ана телендә белем алырга мәҗбүр итә алабызмы? Студентларны төркемнәргә милләтләренә карап тупларгамы; алар авылдагы татар мәктәпләрен бетерүчеләрдән генә тормасмы? Уку йортын тәмамлаучылар хезмәттәшләре белән аралашканда, эш кәгазьләре сызымнар, техника һәм технология, технологик карталар һ. б. белән эшләгәндә кайсы телдә аралашырлар? Һөнәр иясе, татарча укыган белгеч эшне Татарстанда гына таба алачак, базар икътисады (һәм аның юлдашы — эшсезлек) шартларында без аның мөмкинлекләрен чикләмәбезме?

Һәркемгә аңлашыла: кирәкле терминнар эшләнгән булса да, дәреслекләр һәм яхшыукытучылар җитсә да, фән күп кулланылган җитештерү шартларында татар теле белән генә чикләнергә һич тә ярамый, чөнки татар телендә рус телендәге кебек, ә рус телендә, инглиз телендәге кебек, бай фәнни-техник әдәбият юк.

Инглиз телле булмаган күп илләрдә шул телдә укыта торган мәктәпләр ачыла. Төркия меңләгән яшьләрен Европа илләренә, АХШ-ка укырга җибәрә... Ни өчен уз телендә генә уку-укыту күпләрне канәгатьләндерми? Мәсәлән, АКШта 350 меңнән артык читтән килгән студент укый (әлбәттә, инглиз телендә). Анда Латин

Американсыннан чыккан балаларны испан телендә укыта торган гомуми белем мәктәпләре дә оештырыла, әмма һөнәри белем бирү — инглиз телендә.

Һичшиксез, тел өйрәнү өчен җитәрлек акча һәм вакыт бирелсә, безнең студентлар инглиз телен дә рус теле белән бер үк дәрәҗәдә өйрәнә алырлар иде. Моңа шартлар юк, уку йортларыбыз ярлы, техник чаралар җитәрлек түгел, студентларның телгә сәләте да төрлечә. Яшьләр өчен «тел мәйданы» дигән җитди сәбәп та бар.

XX гасыр азагында дөньядагы илләр арасында икътисад һәм мәгълүмат хезмәттәшлеге,интеграция һәм миграция (күчеп йөрү) өчен яңа мөмкинлекләр барлыкка килде. Соңгы ике дистә ел эчендә дөнья базарында «технология» дигән товар күренү белән, хезмәткәрләрне чит илдә укыту һәм яңа технологияләрне үзләштерү ихтыяҗы туды. Дөнья базарында махсус товар — мәгълүмат хасил булды. Шуңа күрә күп илләр (мәсәлән, гарәп дөньясы, Африка, Азия илләре) яшьләрне үз телләрендә генә түгел, башка телләрдә дә эш алып барырга өйрәтәләр. Шулай эшләгәндә алар яңа технологияләрне җиңелрәк үзләштерәләр. 30 ел элек француз яки немец кешеләренең бик азы гына инглиз телен белә иде. Хәзер Париж яки Берлин урамнарында инглизчә сөйләшү еш ишетелә. Бөтен халыкара оешмалар, төрле телләрдә эш алып бара алсалар да, инглиз телендә эшлиләр.

Димәк, һөнәри белемне халыкара (регионара) стандартка туры китерү сорала. Шунсыз кеше эш урынын сайлау хокукыннан мәхрүм була, бу исә демократия принципларына каршы килә.

## III. Татарча терминнар хакында

Татарча һөнәри белем булмаганга күрә, табигать, техник фәннәр өлкәсендә татарча терминология эшләнмәгән; сыналган, тәҗрибәдә тикшерелгән программалар һәм дәреслекләр дә юк диярлек.

Тел белгечләребез терминнар турында күп яздылар, махсус комиссия дә төрпе карарлар чыгарды, әмма терминнар мәсьәләләрен хәл итү бер генә көнлек эш түгел, аны тәртипкә салу өчен еллар кирәк.

Татарстанда яшьләргә башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем татар телендә бирелә башлады, дип фараз итик. Моны башкару өчен беренче нәүбәттә кирәк булган шарт — телне белүче мөгаллимнәр һәм терминология. Дөнья үзгәрү белән, яңа терминнар да туып тора. Рус телендә күп кенә сәяси, икътисади, техник терминнар хәзер дә чит телләрдән алына (*согласие* урынына «консенси»,

секретно, *скрытно* урынына «конфиденциально», *управление* урынына «менеджмент», *вычет* урынына «дисконт» һ. б.).

Татар телендә сүз байлыгы шактый зур. Саф төрки сүзләрдән гайре, рус теле аша кергән чит тел сүзләре дә, үз вакытында иске татар теленә гарәп һәм фарсы телләреннә кергән сузлар дә кулланыла. Ләкин чама булырга тиеш. Мәсәлән, берәүләр — «республика», икенчеләре «җөмһүрият» сүзен куллану яклы. Кайсы термин төгәлрәк — «икътисад»мы, «экономика»мы? Кайсы дөресрәк — «мөхәррир»ме, «редакторымы? Ә бәлки икесе дә кирәктер? «Җиһан» һәм «дөнья» белән дә шул ук хәл. Мондый синонимнарны тәртипкә салырга, кайсы — термин, ә кайсы киң мәгънәле сүз икәнлеген ачыкларга вакыт җитте.

Гуманитар фәннәр буенча шактый нык үскән терминология бар кебек. Эмма ул ни дәрәҗәдә эшләнгән һәм телне үстерү өчен ярарлыкмы? Мәсәлән, дәреслектә «королевство» дигән сүз татар теленә ничек тәрҗемә ителә? «Корольлек»ме? Ләкин бу алынма ич! Татар матбугатында «мәмләкәт» сузан «дәүләт» сүзенең синонимы итеп кулланалар. Иске татар телендә «мәмләкәт» сүзе «корольлек», «патшалык», «ханлык» төшенчәсен аңлаткан. Һәм бу дөрес тә, чөнки аның тамырында «малик» сүзе ята (гарәпчә «король» төшенчәсен аңлата). Гуманитар фәннәрдә мондый эшкәртелмәгән терминнар байтак.

Хәзер татарча әйтү өчен уңайсыз булган сүзләрне алмаштырырлык яңа сүзләр табыла тора. Мәсәлән, «председатепь» сүзе бик уңышлы итеп «рәис» сүзе белән алмаштырылды, «власть»ны «хакимият» диләр. «Больница» сүзенә халык күнеккән, ләкин ул да, «председатель» сүзе кебек үк, татар теленә ятышмый,— аны «бүлнис» дип әйтәләр. «Станция» сүзе дә гадәттә «ыстанса» дип әйтелә.

«Больница» сүзе урынына журналистлар «хастаханахә», «дәвалана», «шифаханә», «сырхауханә», «сихатханә» сүзләрен тәкъдим итәләр.Тик башта һәр яңа терминның мәгънәсен ачыклыйсы иде; авыру белән табиб бер-берсен аңламаслык булмасын инде. Минем фикеремчә, «больница» сүзе «хастаханә», «сырхауханә» дип бирелә ала, ә «шифаханә» — «поликлиника»га, «дәваханә» — «профилакторий»га күбрәк туры килә. Әлбәттә, бу терминнар әле урнашмаган, ләкин бер мәгънәдә еш куллану нәтиҗәсендә, алар сәламәтлек саклау һәм медицина өлкәсендә кабул ителгән термин булып китәчәкләр. Моның өчен иң кулае — медицина уку йортларында татарча укыту. Тик әлеге да баягы — дәреслекләр, мөгаллимнәр,татарча сөйләшүче табиблар, медицина әдәбияты кайда соң?

Төгәл фәннәрдәге атамалар, техник терминнар белән нәрсә эшләргә? Без күбесенчә рус теле аша кергән терминнарны кулланабыз. Татарча техник

терминнар аз, бу күпчелек телләр өчен уртак хәл. Кайбер авторлар терминнарны башка телләрдән күчерә башладылар. Алдарак атап үтелгән җыентык авторлары, техник терминнар турында фикер йөрткәндә, татарча атамаларга мисаллар китерәләр. Мәсәлән, Юлдашев А., Әфләтонов Ә. «герметизация» сүзен уңышлы итеп «томалык» сүзе белән аңлаталар («герметичный» — томалы), «шток поршня»—пешкәк таягы, «шестеренка» — чарык, «лебедка» — чыгыр, »педаль» — табан һ. б ш. терминнар кулланыла. Тик менә «деформация» сүзен татарча «имгәнү» сүзе белән аңлатып булыр микән?

«Профессия» сүзе дә, гәрчә сөйләм телендә кулланылса да, татар сүзе дип саналмый, аны «һөнәр» дип тәрҗемә итәләр. Ләкин «профессия»сүзенең мәгънәсе киңрәк. Профессия — кеше шөгыленең нинди дә булса конкрет хезмәт белән бәйләнмәгән аерым бер төре (мәсәлән, мөгаллим, табиб, мәнаҗер, проектлаучы профессияләре). Ә «һөнәр» татарда — «кул эше». Аның бу мәгънәсе мәкальләрдә дә чагыла: «Һөнәрленең— кулы алтын, акыллының акылы алтын», «һөнәр— кулдагы алтын беләзек» һ. б. ш. Димәк, һөнәрнең тел мәгънәсе — «ремесло». Хәзерге җитештерү өлкәсендә күбрәк акыл көче таләп итела торган профессияләр бар, аларны да «һөнәр» сүзе белән билгеләү дөрес булырмы икән? Ясалма сүзләр (мәсәлән, «профессионализм» сүзе) белән ни эшләргә? «Һөнәрилек» аны алыштыра алыр микән? Профессия сүзен төшереп калдырсак, телебезне ярлыландырмабызмы? Минемчә, ике сүз дә урынлы, тик мәгънә төсмерләрен генә аерырга кирәк.

Күпчелек телләр алынма термин һем сүзләр исәбенә баетыла. Нык үсеш алган телләрдә аларны алмаштырмыйлар. Тик төрекләр генә, ялгышып, «яңа буынны картлардан аердылар». Әле дә үкенәләр. Шул ук вакытта, һәр кешегә таныш булган кайбер әйберләр «милли исем» алалар (дөрес, ешрак сөйләм телендә). «Машина» — барлык Европа телләре өчен диярлек уртак термин (хәтта гарәп телендә дә — «макина»). «Автомобиль»не күп кенә Европа һәм хәтта Азия телләрендә дә «авто» диләр. Ләкин французлар эквивалентлы — «вотюр» сүзен тапканнар, гарәпләр «сәйярә»дип атыйлар, ләкин сөйләшкәндә ешрак «гарәбия» диләр (гарәбә —«арба» дигән сүз).

## Йомгаклау

Татар һәм рус урта мәктәпләре ел саен меңнәрчә яшь кешеләрне укытып чыгара. Алар нинди һөнәрләр үзләштерергә хыяллана соң? Кайда укып белем алырга тели? Күбесе профтех-училищега яки техникумга (республикада шундыйп160 тан артык уку йорты бар) керәләр. Чиректән артыгы укуларын югары мәктәптә дәвам

итә (Татарстанда 20 югары уку йорты бар)ю Анда укучы татар яшьләренең саны 50 нче елларда студентларның 27 процентын тәшкил итсә, 70 нче елларда бу сан 43 кә җитте. Әлбәттә, югары белем бирүче татар уку йортларының абруе зур, алард ататар галимнәре саны да артты. Ә урта һәм башлангыч һөнәри белем турында сүз бармый диярлек. Әйтерсең лә, инженер гына сукалый яки итек тегә, очкыч һәм авто эшләп чыгара. ПТУ һәм техникумнарда галимнәр эшләми, шуңа күрә аларда тел мәсьәләсен күтәрүче дә күренми.

«Корал кемнеке — заман шуныкы», дидек. Иркен тормышка юл ярып баручы халкыбызның коралы — аның һөнәре, белеме «Татарча һөнәри белем бирергәме, бирмәскәме?» дигән сорауга җавап катгый рәвештә уңай булырга тиеш.